**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 июнь № 422

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә һәм аның гаилә әгъзаларына, шул исәптән дәүләт граждан хезмәткәре пенсиягә чыкканнан соң медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турында» 2006 ел, 10 июль, 352 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә һәм аның гаилә әгъзаларына, шул исәптән дәүләт граждан хезмәткәре пенсиягә чыкканнан соң медицина хезмәте күрсәтү тәртибе турында» 2006 ел, 10 июль, 352 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 23 декабрь, 1005 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пункт үз көчен югалтуын танырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына агымдагы елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәтенең кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасыннан файдаланып формалашкан, фамилияләре, исемнәре һәм әтисе исемнәре, шулай ук биләгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләгән затлар исемлеген тапшырырга тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә һәм аның гаилә әгъзаларына медицина хезмәте күрсәтү, шул исәптән дәүләт граждан хезмәткәре пенсиягә чыкканнан соң да, тәртибе турында нигезләмәдә:

1.5 пунктта:

беренче абзацта «Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләрен «гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү» сүзләренә, «учреждениеләрдә» сүзен «оешмаларда» сүзенә алмаштырырга;

икенче абзацта «дәүләт һәм муниципаль амбулатория-поликлиника учреждениеләре» сүзләрен «медицина оешмалары» сүзләренә, «2 нче республика клиник хастаханәсе» сүзләрен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белемнең федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медико-санитария часте» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта «урта яки югары һөнәри белем бирү учреждениеләре» сүзләрен «урта һөнәри һәм югары белем мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 һәм 2.3 пунктларда «2 нче республика клиник хастаханәсе» сүзләрен «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары һөнәри белемнең федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең медико-санитария часте» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта дәүләт һәм муниципаль амбулатория-поликлиника учреждениеләрендә» сүзләрен «медицина оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков